СОВЕТ НИЖНЕУСЛОНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Заводская, д.55, с. Нижний Услон, 422574

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ТҮБӘН ОСЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Завод ур., 55 нче йорт, Түбән Ослан авылы, 422574

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ КАРАР

25.11.2024 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48 46-261

с. Нижний Услон

Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Түбән Ослан җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә Түбән Ослан авылы торак пунктының бер өлешенең халык төркеме инициативасын карап,

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан авылы территориясенең бер өлешендә гражданнардан үзара салым акчасын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2024 елның 5 декабренә гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«2025 елда Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Түбән Ослан торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 20 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә сез ризамы?:

- Каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, Түбән Ослан торак пункты чикләрендә рөхсәтсез чүплекләрне бетерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Түбән Ослан авылы Карл Маркс урамындагы 47 нче йорт янында халык җыенын 14.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Түбән Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В. Архиреев